КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 август г.Казань № 925

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 октябрь, 731 нче; 2014 ел, 29 ноябрь, 930 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 982 нче; 2015 ел, 4 август, 566 нчы; 2015 ел, 5 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 27 сентябрь, 689 нчы; 2017 ел, 24 апрель, 241 нче; 2017 ел, 28 июнь, 450 нче; 2018 ел, 26 июнь, 520 нче; 2018 ел, 19 декабрь, 1173 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 754 нче; 2020 ел, 28 гыйнвар, 47 нче; 2020 ел, 16 июль, 601 нче; 2021 ел, 29 апрель, 297 нче; 2021 ел, 13 сентябрь, 863 нче, 2021 ел, 30 декабрь, 1327 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="16">«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Ел</td><td colspan="2">Карала торган акча күләме, млн.сум</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджеты</td><td>федераль бюджет</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>39,324</td><td>21,6008</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>32,724</td><td>17,9678</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>42,624</td><td>18,2494</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>40,371</td><td>9,1068</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>52,2787</td><td>10,3585</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>53,6144</td><td>10,8317</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>26,5596</td><td>10,5074</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>47,9484</td><td>10,2759</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>53,3586</td><td>10,6537</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>47,2486</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>52,6586</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>46,2686</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>534,9785</td><td>119,552</td></tr>
<tr><td colspan="3">Программаны финанслауның гомуми күләме 654,5305 млн. сум тәшкил итә, шулардан:<br>534,9785 млн. сум - Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;<br>119,5520 млн.сумы – федераль бюджет акчасы.<br>Искәрмә. Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле финанс елына һәм план чорына тиешле дәрәҗәләрдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук Программа чараларын финанслашуга федераль бюджеттан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;</td></tr>
</table>

Программаның I бүлегендә:

егерме дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2020 – 2023 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында” 2020 ел, 25 август, 730 нчы карары белән расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2020 – 2023 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә гамәлгә ашырыла» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2020 – 2024 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында” 2020 ел, 25 август, 730 нчы карары белән расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2020 – 2024еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә гамәлгә ашырыла» сүзләренә алмаштырырга;

егерме алтынчы абзацта «2014 - 2025 елларга халык сәнгать һөнәрләрен саклап калу, өйрәнү һәм үстерү» ярдәмче программасы» сүзләрен «2014 - 2020 елларга халык сәнгать һөнәрләрен саклап калу, өйрәнү һәм үстерү» ярдәмче программасы» сүзләренә алмаштырырга;

III бүлекнең алтмыш өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

Программаның IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программа чараларын финанслау Татарстан Республикасы бюджеты һәм федераль бюджет акчасы исәбеннән гамәлгә ашырылачак.

Программада программа чараларын тормышка ашыру өчен бюджеттан тыш акча (эшмәкәрләр, иганәчеләр акчасы) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчасын җәлеп итү мөмкинлеге каралган.

| Ел | Карала торган акча күләме, млн.сум | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджеты | федераль бюджет |
| 2014 | 39,324 | 21,6008 |
| 2015 | 32,724 | 17,9678 |
| 2016 | 42,624 | 18,2494 |
| 2017 | 40,371 | 9,1068 |
| 2018 | 52,2787 | 10,3585 |
| 2019 | 53,6144 | 10,8317 |
| 2020 | 26,5596 | 10,5074 |
| 2021 | 47,9484 | 10,2759 |
| 2022 | 53,3586 | 10,6537 |
| 2023 | 47,2486 | - |
| 2024 | 52,6586 | - |
| 2025 | 46,2686 | - |
| Барлыгы | 534,9785 | 119,552 |

Программаны финанслауның гомуми күләме 654,5305 млн.сум тәшкил итә, шулардан:

534,9785 млн. сум - Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

119,552 млн.сумы – федераль бюджет акчасы.»;

Программаның 4 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин